ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 август, 2017 ел № 18/11

Шәһәр Советының 2008 елның 25 нче сентябренлә кабул ителгән 34/17 санлы Карары белән расланган шәһәр Хакиме стипендиясен булдыру турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендә кабул ителгән «Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турындагы Нигезнамәне раслау турында» 25/23 санлы Карарына нигезләнеп

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1 Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябренлә кабул ителгән 34/17 санлы Карары белән расланган шәһәр Хакиме стипендиясен булдыру турындагы Нигезнамәнең (Шәһәр Советының 25.12.2008 № 37/5, 26.05.2010 № 50/9, 09.11.2016 № 11/11 Карарлары редакциясендә) 9 пункты 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) иҗтимагый эшчәнлек өлкәсендә - 20 стипендия, бер стипендия 2000 сум.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев